**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5168**
**08.10.2019**

Муниципаль ихтыяҗлар өчен
җир участогын кире алу турында

Җирле әһәмияткә ия объектны – Иске Сарман урамы буенча автомобиль юлын реконструкцияләү максатында, Россия Федерациясе Җир кодексының 11, 49, 56.2, 56.3, 56.6, 56.7, 56.8, 56.10 маддәләре, Шәһәр Советының 2006 елның 27 июнендәге 14/4 нче карары белән расланган шәһәрнең Генераль планы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, БСИ адресы буенча, Сарманга илтүче автомобиль юлы «Подряд» тресты каршында урнашкан «Техно-Союз» ҖЧҖдә аренда хокукындагы, мәйданы 100 кв.м (кадастр номеры 16:52:080503:221), рөхсәт ителгән файдалану төре – «сәүдә павильоны булган тукталыш комплексы өчен» булган җир участогын кире алырга.

2. Муниципаль ихтыяҗлар өчен, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән кире алына торган җир участогында урнашкан «Техно-Союз» ҖЧҖнең милекчелек хокукындагы күчемсез милек объектын – «Сәүдә павильоны булган тукталыш комплексы»н (кадастр номеры 16:52:080503:2379) кире алырга.

3. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә:

1) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

2) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә, законда билгеләнгән тәртиптә аның күчермәсен әлеге карарның 1, 2 пунктларында күрсәтелгән кире алына торган күчемсез милек объектларына хокукы булган затка җибәрергә;

3) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр

һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Яр Чаллы бүлегенә җибәрергә;

4) кире алу нәтиҗәсендә туктатылган хокукларны һәм китерелгән зыянның күләмен бәяләү, шулай ук кире алына торган күчемсез милек объектына алмашка бирелә торган күчемсез милекне бәяләү өчен бәяләүче оешманы билгеләргә;

5) җир участогын кире алу буенча эш йомгаклары нигезендә, муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын һәм анда урнашкан күчемсез милек объектын кире алу турында килешенү әзерләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин